

«Участковый» сvзе «участие» дигән-нән алынган. Катнашмый гына ничек инде барлыкка килгән киеренкелекне, мәсәлән,ир белән хатын арасында туган киеренкелекне,авыл халкынын законлы хокукларын саклый, тәртип һәм кануннарны бозучылар белән корәшсен инде?
Ренат Рәшит улы Сюндюков – участковый полиция вәкиле, авыл халкынын законлы хокукларын саклый, тәртип һәм кануннарны бозучылар белән корәшә. Темников районы полиция бvлегендә 2011 елдан алып хезмәт итә. Анын участогында 26 авыл һәм анда яшәvче 2 мен 600 кеше. Кvпчелек халык дус-тату яши, әмма бар эчкечеләр, сугышчылар, наркоманнар, акылсызлар- психлар, бар гаиләдә дебоширлар; баларына кайгы китергән тәртипсез әти-әниләр дә юк тvгел.  Ренат Рәшит улынын биш еллык участковый эш тәжрибәсе тартмасында нинди генә авыр вакыйгалар белән очрашу юк! Тагы ярты елга бер тапкыр булса да халык жыены vткәреп эшләнелгән эшләр турында отчет тоту, атнага берничә тапкыр гражданнарны шәхси кабул итv, участковый формасы «акылга килергә» ярдәм иткәннәрнен һәрберсенә кереп чыгу һәм башка, һәм башка торле вазыйфалар йокләтелгән ана.
Яшьлеккә хас энергия һәм омтылышлар белән башлап жибәрә Сюндюков Ренат Рәшит улы участковыйлык эшен. Башта анын карамагында булган авылларында яшәvчеләр белән танышып чыга, кем нинди уйлар белән яши, шуны анларга тырыша. Участогында ботен нәрсәне контрольдә тота башлый, тырышып эшли. Халык та яшь полицейскины әйбәт кабул итә.
Тыгыз эш графигына исләр китә. Ана авыр тvгелме дигән сорау да туа. «Юк, - ди Ренат Рәшит улы. Эчке эшләр бvлегенә 2003нче елны, Армия сафында хезмәттән сон, теләп килдем. Башта водитель буларак урнашкан идем. Сонрак, МВДнын Тvбәншәһәр академиясен тәмамладым. Участковый хезмәте кызыклы мина һәм халыкнын ышанычын да яулый белергә кирәк бит».
Темников районы Участок бvлекчәсендә участковыйлар бер-берсен тулысынча алыштыра ала. Хезмәт ялына-отпускага, коллегалары оч айга белем камилләштерегә дип

укырга киткән чакта анын участогы да синеке була. Эш ике тапкыр кvбәя. Бу вакыт анда нәрсә булганы, нинди вакыйгалар белән тулганы очен Син жавап кайтарасын. Шуна остәп, кәгазь эшләре дә койрык буларак ялганып килә. «Ренат Ряшидович булдыра, - дигән бәяне М. И. Николаев, шәхси состав белән житәкчелек иткән ОВД начальнигы ярдәмчесе ишеттерә. – Хәзер, бvлек житәкчесе ялда чакта, аны алмаштыра». Тагы ОВД эзләv-оператив группасы составында 24 сәгать буена дежур тора алар. Эшләрнен бихисап булуына карамастан, бик тырыш һәм тәртипле гаиләдә туып vскән полиция капитаны Ренат Рәшит улын оендә һәрвакыт тормыш иптәше белән кызы котеп ала. Нindирәк жинаятьләр була авыл жирендә дигәч ул: «Авыл халкы тәртипле, нигездә законга буйсынып яши, жинаять кылунын начар гамәл икәнен кvнеленә сендергән. Шулай да хокук тәртибен бозу очраклары гел булып тора. Авыл жирендә бу нигездә кеше милкен урлау: шәхси хужалыклардан бортек, фураж, металл ватыгы итеп тапшырырлык нәрсәләр, терлек... исерек килеш бәйләнешеп китеп башка кеше сәламәтлегенә зыян китерv, хәтта vтерv очраклары да булгалый. Гаиләдә чыккан жәнжаллар да кайчак полиция катнашыннан башка гына тынмый. Торлесе була инде, участковыйга эшсез торырга туры килми».
Бер участокта 5 ел эшләп, Ренат Рәшит улы Сюндюков участогында яшәvчеләрне бик яхшы белеп бетергән, билгеле. Участокка кергән авыллар халкы да аны vз иткән. “Ул бит һәркем белән аралаша, иренеп тормый, ойләргә дә керә, яше-карты белән уртак тел табып сойләшә,”– диләр участковыйлары турында Тархан авылы жирлеге советында.

**Н.Хәлил**